**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ГОРОДА ЛАИШЕВО**

422610 г.Лаишево,
ул. Коммунальная, д.3
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘР СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

---

2022елның 31 октябре 40 номер

# К А Р А Р

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында»**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль берәмлек башлыгы урынбасарының, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи айлык акчалата бүләк күләмнәрен арттыру турында» карары нигезендә, Лаеш муниципаль районы Советы **карар кабул итте**:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт вазыйфалары буенча «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләүгә чыгымнарны булдыру нормативлары турында» 2018 елның 10 апрелендәге 99 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карары белән расланган вазыйфаи окладлары күләмнәрен 2022 елның 1 октябреннән 1,04 тапкырга арттырырга.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен әлеге карарның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,04 мәртәбә индексацияләргә һәм аны 11 958 сум күләмендә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль

районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының план-бюджет комиссиясенә һәм икътисадый үсешенә йөкләргә.

**Башлык – Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**